СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

05.02.2026 Баулы шәһәре №32

2026 елга Баулы муниципаль районы
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
Фаразлау планы (программасы) турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә,Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планын (программасын) 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының Икътисадый үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль район Советының
2026 елның 5 февралендәге
32 номерлы карарына
1 нче кушымта

2026 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Баулы муниципаль районының 2026 елга муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Баулы муниципаль районы милкенең структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

1.3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. Баулы муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштыру үткәрелмәгән, 2025 елга Баулы муниципаль районының Фаразлау планына (программасына) кертелгән объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.3. Муниципаль милектәге муниципаль казна предприятиеләрен һәм акцияләрен хосусыйлаштыру 2026 елда планлаштырылмый.

2.4. Хосусыйлаштыруның фаразлау планы гамәлдә булган вакытта 2026 елда хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлегенә яңа күчемсез мөлкәт объектлары өстәлергә мөмкин.

2.5. 2026 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт (1 нче таблица).

1 нче таблица

| № п/п | Объект атамасы | Урнашу урыны (Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы) |
|---|---|---|
| 1 | Кадастр номеры 16:55:010308:56, гомуми мәйданы 466,6 кв.м. булган торак булмаган  запас частьләр склады | Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Кадастр номеры 16:55:010308:69 гомуми мәйданы 24 970,0 кв.м. булган җир участогы | Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |